ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 апрель 2019ел № 1746

Акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргән гражданнар исәбенә кертү критерийларын һәм зыян күргән гражданнар реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 12 августындагы 560/пр санлы Приказы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2017 елның 6 сентябрендәге 5212 нче карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 7 декабрендәге 7600 нче, 2018 елның 23 октябрендәге 6287 нче карарлары редакциясендә) расланган акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, | Реестрга кертү өчен гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>1) шәхесне раслаучы документ күчермәсе; | Кагыйдәләрнең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 2) зыян күргән граждан һәм торак бүлмәне зыян күргән гражданга тапшыру буенча йөкләмәне үтәмәгән проблемалы объектны төзүче арасында хокук мөнәсәбәтләре барлыкка килүне раслаучы өлешләп төзүдә катнашу килешүенең күчермәсе һәм тапшыру килешүенең күчермәсе (килешү буенча өлешләп төзүдә катнашучы тарафыннан таләпләр хокукы тапшырылган очракта);<br>3) проблемалы объектка карата төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүе һәм тапшыру килешүе (килешү буенча өлешләп төзүдә катнашучы тарафыннан таләпләр хокукы тапшырылган очракта) буенча зыян күргән граждан тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен раслаучы түләү документларының күчермәләре;<br>4) төзүчегә карата төзүченең банкротлыгы турында эштә кулланылучы процедураларның берсе кертелгән очракта, зыян күргән гражданның проблемалы объектны төзүчегә карата таләпләрен торак бүлмәләрне тапшыру турында кредиторларның таләпләре реестрына кертү турында законлы көченә кергән суд актының күчермәсе. | |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин